КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 28 август г.Казань № 1032

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерү турындагы үтенечнамә формасын һәм аңа теркәлә торган документлар составын раслау хакында» 2006 ел, 25 октябрь, 523 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерү турындагы үтенечнамә формасын һәм аңа теркәлә торган документлар составын раслау хакында» 2006 ел, 25 октябрь, 523 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 28 март, 112 нче; 2008 ел, 14 апрель, 232 нче; 2009 ел, 1 июнь, 353 нче; 2010 ел, 20 апрель, 279 нчы; 2010 ел, 19 август, 667 нче; 2011 ел, 29 август, 725 нче; 2012 ел, 13 февраль, 110 нчы; 2012 ел, 25 май, 418 нче; 2013 ел, 26 сентябрь, 684 нче; 2014 ел, 6 август, 572 нче; 2015 ел, 2 апрель, 211 нче; 2015 ел, 27 июль, 546 нчы; 2016 ел, 2 ноябрь, 805 нче; 2017 ел, 22 апрель, 237 нче; 2018 ел, 29 гыйнвар, 49 нчы; 2018 ел, 12 июль, 564 нче; 2018 ел, 27 сентябрь, 867 нче, 2019 ел, 5 ноябрь, 1014 нче, 2021 ел, 6 август, 684 нче, 2022 ел, 22 июнь, 596 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта:

икенче абзацка «гамәлгә ашыручы орган» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасында» сүзләрен өстәргә;

өченче абзацта «30 көн эчендә» сүзләрен «законда билгеләнгән вакытта» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктта «министрлыклар, ведомстволар» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга.

әлеге карар белән расланган Авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерү турындагы үтенечнамә формасын яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә);

әлеге карар белән расланган Авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерү турындагы үтенечнамәгә теркәлә торган документлар составында:

9 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сорала торган җир кишәрлегендә урнаштыру күздә тотыла торган федераль әһәмияттәге объектлар (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 10 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән өлкәләрдә), җирле әһәмияттәге объектлар, республика әһәмиятендәге объектлар расланган территориаль планлаштыруның расланган документларына, территорияне планлаштыру документларына (булганда) туры килгәндә җир кишәрлеген бер категориядән икенчесенә күчергән очракта муниципаль берәмлекнең башкарма-күрсәтмә органы. Килешү тиешле дәрәҗәдәге территориаль планлаштыруның расланган документыннан, шарт билгеләрен, сорала торган җир кишәрлегенең чикләрен күрсәтеп, вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан имзаланган өземтәләрне теркәп тапшырыла. «Җирләрне яисә җир кишәрлекләрен бер категориядән икенчесенә күчерү турында» 2004 елның 21 декабрендәге 172-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 4, 7, 9 пунктлары нигезендә җирләрне бер категориядән икенчесенә күчергән очракта килештерү мондый объектларны урнаштыруның башка вариантларының булмавын раслый торган документ кушымтасы белән тапшырыла.»;

15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. Күчемсез милек объектларының кадастр бәясен билгеләү вәкаләтләре бирелгән оешма әзерләгән җир кишәрлегенең кадастр бәясен исәпләү турындагы документ («Җирләрне яисә җир кишәрлекләрен бер категориядән икенчесенә күчерү турында» 2004 елның 21 декабрендәге 172-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 6, 7, 8 пунктлары нигезендә бер категориядән икенчесенә күчерүгә бәйле очраклардан тыш) ***.»;

«*» астөшермәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«***Җир кишәрлегенең кадастр бәясен исәпләү турында гариза бирүче тапшырмаган очракта, документ вәкаләтле орган тарафыннан соратып алына.»;

түбәндәге эчтәлекле 16 пункт өстәргә:

«16. Федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка документлар.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2006 ел, 25 октябрь, 523 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 28 август, 1032 нче
карары редакциясендә)

Форма

Татарстан Республикасы Җир
һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрлыгы

## Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясеннән җир кишәрлеген башка категориягә күчерү турында үтенечнамә

_____________________________________________________________ сорый җир
(гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта) яисә юридик затның атамасы)
кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән күчерүне гамәлгә ашыру ___________________________________ гектар
кадастр номеры белән __________________________________________________________,
хокукта булган ________________________________________________________________
(булган хокукның исеме)

___________________________________________________________________________
______ (җирдән файдаланучының исеме)

Татарстан Республикасы ______________________________ районы территориясендә
(муниципаль район исеме)
җирләр категориясенә __________________________________________________________
(җир кишәрлеген күчерү планлаштырыла торган

___________________________________________________________________________
җирләр категориясе күрсәтелә)

_____________________________________________________________________ өчен .
(максатчан билгеләнеш)

Күчерүнең нигезе:

1) расланган территориаль планлаштыру документына туры килә ______________________________________________;
(карар реквизитлары)

2) объектларны урнаштыру вариантлары юк, бу раслана __________

___________________________________________________________________________.
муниципаль берәмлекнең башкарма-боеру органы документының реквизитлары (җирләрне бер категориядән икенчесенә күчерү очракларында «Җирләрне яисә җир кишәрлекләрен бер категориядән икенчесенә күчерү турында» 2004 елның 21 декабрендәге 172-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 4, 7, 9 пунктлары нигезендә күрсәтелә)

| | |
|---|---|
| Заявка бирүченең почта адресы | |
| | |
| Элемтәгә керү өчен телефон | |

Әлеге үтенечкә документлар тасвирлама нигезендә бирелә.
Гариза бирүченең (ей), вәкиленең «___» № ________________________ ышанычнамәсе буенча имзалары

____________________________________________________________/________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда) (имзасы)

М.У. (булганда)

________________________________